СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**26 март, 2024 ел** **№ 396**

**Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфаларын биләүгә конкурс уздыру буенча Бердәм комиссия һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Бердәм аттестация комиссиясен төзү турында» 2022 елның 16 маендагы 163 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Биектау муниципаль районы җирле үзидарә органнарында гражданнарның муниципаль хезмәткә урнашуга тигез мөмкинлек өлешендә муниципаль хезмәтнең төп принципларын гамәлгә ашыру максатларында, «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» 2007 елның 2 мартындагы 25-ФЗ номерлы Федераль законга, Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Уставына, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» 2017 елның 13 апрелендәге 138 номерлы карарына, кадрлар эше буенча аерым функцияләр тапшыру турында төзелгән килешүләргә таянып, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Советы

**КАРАР ИТТЕ:**

1. Биектау муниципаль районы Советының 2022 елның 16 маендагы 163 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының җирле үзидарә органнарында муниципаль хезмәтнең вакантлы вазыйфасын биләүгә конкурс уздыру тәртибе турында нигезләмәгә (26.08.2022 № 196, 23.08.2023 № 315 карарлары редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 5 пунктның «г» пунктчасын төшереп калдырырга

1.2. 1 нче кушымтаның 14 пунктындагы «д», «ж», «з» пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«д) индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документ, хезмәт шартнамәсе (контракт) беренче тапкыр төзелгән очраклардан тыш;»;

«ж) хәрби исәпкә алу документлары - запаста торучы гражданнар һәм хәрби хезмәткә чакырылырга тиешле затлар өчен;»;

«з) муниципаль хезмәткә керүгә комачаулык итә торган авыруы булмау турында медицина оешмасы бәяләмәсе;»;

1.3. 1 нче кушымтаның 13 пунктына түбәндәге эчтәлекле «ж» пунктчасын өстәргә:

«ж) хезмәт шартнамәсе проекты.»;

2.1. Муниципаль хезмәткәрләргә аттестацияләү уздыру турындагы Нигезләмәнең 3 бүлегенең 22 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«22. Муниципаль хезмәткәрнең вазыйфасын түбәнәйтү белән риза булмаган яисә аның ризалыгы белән муниципаль хезмәтнең башка вазыйфасына күчерү мөмкин булмаган очракта, яллаучы (эш бирүче) вәкиле, аттестация көненнән бер айдан да артык булмаган срокта аттестация нәтиҗәләре белән расланган квалификациясе җитәрлек булмау сәбәпле, биләгән вазыйфага туры килмәве белән бәйле рәвештә аны муниципаль хезмәттән азат итәргә мөмкин. Күрсәтелгән срок узганнан соң муниципаль хезмәткәрне эштән азат итү яисә аны әлеге аттестация нәтиҗәләре буенча вазыйфасында түбәнәйтү рөхсәт ителми.»

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы» мәгълүмати сайтында http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адрес буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф. Хисамутдинов